**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОДАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КЫРЫК ИКЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 5**

Кодаш авылы 20 май 2019 ел

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 февралендәге Кодаш авыл җирлеге Советының XLI сессиясенең №2 карарына үзгәрешләр кертү турында**

---

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп

**Кодаш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 февралендәге Кодаш авыл җирлеге Советының XLI сессиясенең №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 4 бүлектә:

*- 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:*

«4. Халык алдында тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге

башлыгы (Кодаш авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча үткәрелә.

Кодаш авыл җирлеге Советы яки халык инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар Кодаш авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә Кодаш авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча үткәрелүчесе (Кодаш авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) – Кодаш авыл җирлеге башлыгы тарафыннан.».

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кодаш авыл җирлеге башлыгы** **Г.А.Хайсарова**